КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 606

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән расланган үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 10 декабрь, 932 нче; 2017 ел, 14 ноябрь, 873 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1133 нче; 2020 ел, 30 июль, 636 нчы; 2020 ел, 20 ноябрь, 1035 нче; 2021 ел, 26 апрель, 286 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 1.11 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«социаль контракт төзегән елга Татарстан Республикасында билгеләнгән эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләме – эш эзләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән социаль контракт төзегән, шулай ук граждан тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңү буенча башка чараларны гамәлгә ашыру чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән социаль контракт төзегән гражданнарга (биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдән тыш);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин